Балаларның белемен үстерүдә Интернет челтәренең роле

Мәгариф – җәмгыятьнең үсешендә төп роль уйный. Бүгенгесе көндә Татарстан Республикасында бер электрон система тудырылды. Ул мәгариф ресурсларына иркен һәм оператив рәвештә керергә мөмкинлек бирә. Интернет челтәренең һәм интернет технологияләренең интенсив үсеше төрле төрдәге информацион ресурслар һәм интернет хезмәтләр тудыруга китерде.

Шундыйларга киң эчтәлекле информацион ресурс хезмәтләре белән баетылган бердәм интернет челтәре – Татарстан Республикасының электрон мәгариф порталы. Шушы порталны кулланучыларга –укытучыларны кертеп булыр иде.

Татарстан Республикасындагы электрон мәгариф порталының төп максаты булып мәгърифәт үсешен алга җибәрү, аның сыйфатын үстерү, ата-ананың мәгариф системасына игътибарын арттыру тора.

Интернет — ул электрон информацияләр белән аралашу чарасы булып тора.Һәрбер интерент белән эшли белүче укытучы һәм укучы үзенә кирәк булган мәгълүматны интернеттан таба ала. Татар теле – ул специфик предмет. Әгәр элек татар теле укытучысы материал эзләү процесында кыенлыклар тойган булса, хәзер ул икеләнмичә электрон мәгариф порталын ача ала. Бу исә үз чиратында, дәресне кызыклы, мавыктыргыч итә.

Мин электрон мәгариф порталында бигрәк тә "Цифрлы белем бирү ресурс»ларын бүлеген актив кулланам. Биредә мин кирәк булган теманы сайлыйм һәм укучылар белән ишетеп аңлау, уку, диалог кебек сөйләм эшчәнлеге төрләрен камилләштерәм.Шулай ук бу ресурсны файдаланып, балалар белән дөрес аваз әйтелешен ныгытам. Тагын татар теле дәреслекләренә электрон кушымталар бүлегеннән файдаланам. Бу бүлектә дәреслекләрдә бирелгән күнегүләр тагын да үтемлерәк булсын өчен, өстәмә биремнәр, күнегүләр бирелгән. Шунда ук үткән дәрес темаларын да ныгыту өчен күнегүләр бирелә.

Информацион системада «Бала» диеп исемләнгән интерактив мультимедия тавышлы китапханә булдырылды. Ул үзенә югары дәрәҗәдә потенциаль мөмкинлекләр туплаган һәм татар теле дәресендә куелган дидактик максатларга уңышлы ирешергә мөмкинлек бирә. Мультипликацион фильмнарны ww.BALA.RF.ru сайтын куллану белән минем дәресләрем тагын да мавыктыргыч, кызыклы, эчтәлекле үтә. Мультипликацион фильмнарны ике дәүләт телендә карарга була.

Уку предметын әйбәт үзләштерү өчен мәктәптә бирелгән сәгатьләр генә җитми, өстәмә сәгатьләр кирәк. Мондый очракта электрон мәгариф системасында бирелгән виртуаль факультативлар барлык укучыларга өстәмә эшләргә ярдәм итә.

Виртуаль факультативлар укучыларның фәнгә кызыксынуын ныгыта, белемен һәм сәләтен үстерә, эзләнү эшенә этәрә.

Электрон Мәгариф системасы киләчәк буынга белемен камилләштерү өчен бетмәс – төкәнмәс мөмкинлекләр ачты!

Мин шушы ресурслардан барлык укучы һәм укытучыларга да кулланырга киңәш итәр идем.

Сахапова Фәрдия Алгатовна
Чистай шәһәре “1нче гимназия”нең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы